**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Түбән Үрәс авыл җирлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

**2024 елның 11 ноябре** **№ 11**

**Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлегенең Түбән Үрәс авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кукмара муниципаль районының Түбән Урэс авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2024 елның 22 ноябренә 10 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлегенең Түбән Үрәс авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының үткәрүен билгеләргә. Халык җыенын Түбән Үрәс авылы, Парк ур., 6 йорт адресы буенча урнашкан авыл Мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Сез 2025 елда Кукмара муниципаль районының Түбән Үрәс авыл җирлеге Түбән Үрәс авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан; 1 төркем инвалидларыннан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 2000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу);
- урамнарны яктырту җайланмасы (энергияне саклый торган лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү);
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту; (җәйге вакытта юлларны кардан чистарту һәм территорияләрне чабу; ягулык-майлау материаллары сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү);
- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау; (материаллар сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, проект-смета документлары һәм технадзорны гамәлгә ашыру);

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Халык җыеннын үткәрүгә җаваплы итеп Түбән Үрәс авыл җирлеге башкарма комитететын билгеләргә.

4. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Түбән Үрәс авыл җирлеге башлыгы В.Г. Сәфәров

ОГРН 1021607753133
ИНН 1623002015